**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » май 2019 с. Тюлячи № 283

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 29 ноябрендәге «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге турында»гы 675 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми законнары турында»гы 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131 санлы Федераль законга, Татарстан Республикасының 2006 елның 19 декабрендәге 80 санлы Административ хокук бозулар турындагы кодексына, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 августындагы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45 санлы законына нигезләнеп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 29 ноябрендәге «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге турында»гы 675 санлы карары (2014 ел 19.03. № 137, 2014 ел 16.10. № 459, 2015 ел 01.07. № 366, 2017 ел 29.12. № 823 карарлары редакциясендә) кушымтасына үзгәреш кертергә һәм Татарстан Республикасының 2006 елның 19 декабрендәге 80 санлы Административ хокук бозулар турындагы кодексына нигезләнеп, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Административ хокук бозулар турында беркетмә төзәргә вәкаләтле вазифаи затларының исемлеген кушымта нигезендә бирергә.

2. Район Башкарма комитетының кадрлар белән эшләү һәм муниципаль хезмәт секторына (Закирова Г.И.) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларны әлеге карар белән имза куйдырып таныштырырга һәм вазыйфаи затларның вазыйфаи инструкцияләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 «13» май 283 санлы
карарына кушымта

## Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасының 2006нчы елның 19нчы декабрендәге 80нче санлы Административ хокук бозулар турындагы кодексына нигезләнеп Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлары исемлеге

| № п/п | Вазифаи затлар | Статьялар исеме |
|---|---|---|
| 1. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары | Статья 2.1. КоАП ТР. Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактасында үзенең исеме һәм мәгълүмат урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата).<br>Статья 2.4. КоАП РТ. Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр.<br>Статья 2.5. КоАП РТ. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү.<br>Статья 2.8. КоАП ТР. Этил спирты булган өйдә эшләнгән продукцияне сату һәм (яки) сату максатларында җитештерү.<br>Статья 2.14. КоАП ТР. Татарстан Республикасы территориясендә тәмәке эшләнмәләрен күпләп һәм ваклап сатуны тыюны бозу.<br>Статья 2.15. КоАП ТР. Терроризмны профилактикалау, аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) юкка чыгару буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу.<br>Статья 3.2. КоАП ТР. Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу.<br>Статья 3.4. КоАП ТР. Урам, квартал эчендәге яктырту кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.5. КоАП ТР. Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу.<br>Статья 3.6. КоАП ТР. Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.8. КоАП ТР. Төнге сәгатьләрдә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу.<br>Статья 3.10. КоАП ТР. Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Статья 3.11. КоАП ТР. Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү буенча чаралар күрү таләпләрен үтәмәү.<br>Статья 3.14. КоАП ТР. Мәдәни-тамашачараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу.<br>Статья 3.15. КоАП ТР. Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү.<br>Статья 8.2. КоАП ТР:<br>- КоАП РФ 19.4 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.4.1 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.5 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.7 статьясы белән каралган хокук бозулар турында беркетмәләр |
| 2. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары | Статья 2.4. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр.<br>Статья 2.5. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү.<br>Статья 2.8. КоАП ТР. Этил спирты булган өйдә эшләнгән продукцияне сату һәм (яки) сату максатларында җитештерү.<br>Статья 2.14. КоАП РТ. Татарстан Республикасы территориясендә тәмәке эшләнмәләрен күпләп һәм ваклап сатуны тыюны бозу.<br>Статья 2.15. Терроризмны профилактикалау, аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) юкка чыгару буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу.<br>Статья 3.3. КоАП ТР. Җирасты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.6. КоАП ТР. Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.8. КоАП ТР. Төнге сәгатьләрдә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу.<br>Статья 3.10. КоАП ТР. Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.11. КоАП ТР. Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү буенча чаралар күрү таләпләрен үтәмәү.<br>Статья 3.14. КоАП ТР. Мәдәни-тамашачараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу.<br>Статья 3.15. КоАП ТР. Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү.<br>Статья 8.2. КоАП ТР.:<br>- КоАП РФ 19.4 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.4.1 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.5 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.7 статьясы белән каралган хокук бозулар турында беркетмәләр |
| 3. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең | Статья 2.1. КоАП ТР. Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт |

| | | |
|---|---|---|
| | социаль мәсьәләләр буенча урынбасары | органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактасында үзенең исеме һәм мәгълүмат урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата).<br>Статья 2.15. Терроризмны профилактикалау, аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) юкка чыгару буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу |
| 4. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр белән идарә итүчесе | Статья 2.1. КоАП ТР. Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактасында үзенең исеме һәм мәгълүмат урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата).<br>Статья 2.4. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр.<br>Статья 2.5. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү.<br>Статья 2.6. КоАП ТР. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү.<br>Статья 2.7. КоАП ТР. Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу.<br>Статья 2.8. КоАП ТР. Этил спирты булган өйдә эшләнгән продукцияне сату һәм (яки) сату максатларында җитештерү.<br>Статья 2.14. КоАП ТР. Татарстан Республикасы территориясендә тәмәке эшләнмәләрен күпләп һәм ваклап сатуны тыюны бозу.<br>Статья 3.4. КоАП ТР. Урам, квартал эчендәге яктырту кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.6. КоАП ТР. Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.10. КоАП ТР. Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.11. КоАП ТР. Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү буенча чаралар күрү таләпләрен үтәмәү.<br>Статья 3.14. КоАП ТР. Мәдәни-тамашачараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу.<br>Статья 3.15. КоАП ТР. Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү.<br>Статья 8.2. КоАП ТР.:<br>- КоАП РФ 19.4 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.4.1 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.5 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.7 статьясы белән каралган хокук бозулар турында беркетмәләр |
| 5. | Теләче муниципаль | Статья 2.1. КоАП ТР. Телләр турында Татарстан |

| | | |
|---|---|---|
| | районы Башкарма комитетының юридик бүлек начальнигы | Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактасында үзенең исеме һәм мәгълүмат урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата).<br>Статья 2.4. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр.<br>Статья 2.5. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү.<br>Статья 2.6. КоАП ТР. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү.<br>Статья 2.7. КоАП ТР. Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу.<br>Статья 3.2. КоАП ТР. Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу.<br>Статья 3.4. КоАП ТР. Урам, квартал эчендәге яктырту кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.6. КоАП ТР. Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.10. КоАП ТР. Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.11. КоАП ТР.Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү буенча чаралар күрү таләпләрен үтәмәү.<br>Статья 3.14. КоАП ТР. Мәдәни-тамашачараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу.<br>Статья 3.15. КоАП ТР. Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү.<br>Статья 8.2. КоАП ТР:<br>- КоАП РФ 19.4 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.4.1 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.5 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.7 статьясы белән каралган хокук бозулар турында беркетмәләр |
| 6. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлек начальнигы | Статья 2.6. КоАП ТР. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү.<br>Статья 2.7. КоАП ТР. Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу |
| 7. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасы рәисе | Статья 4.4. КоАП ТР. Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү тәртибен бозу һәм күрсәтелгән объекттан файдалану.<br>Статья 8.2. КоАП ТР:<br>- КоАП РФ 19.4 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.4.1 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.5 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.7 статьясы белән каралган хокук бозулар турында беркетмәләр |
| 8. | Теләче муниципаль районы Башкарма | Статья 3.2. КоАП ТР. Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу. |

| | | |
|---|---|---|
| | комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече | Статья 3.5. КоАП РТ. Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу |
| 9. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы | Статья 2.1. КоАП ТР. Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма элмә тактасында үзенең исеме һәм мәгълүмат урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата).<br>Статья 2.4. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр.<br>Статья 2.5. КоАП ТР. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү.<br>Статья 3.4. КоАП ТР. Урам, квартал эчендәге яктырту кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.6. КоАП ТР. Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.10. КоАП ТР. Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 3.11. КоАП ТР. Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү буенча чаралар күрү таләпләрен үтәмәү.<br>Статья 3.14. КоАП ТР. Мәдәни-тамашачараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу.<br>Статья 3.15. КоАП ТР. Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү.<br>Статья 4.4. КоАП ТР. Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү тәртибен бозу һәм күрсәтелгән объекттан файдалану.<br>Статья 8.2. КоАП ТР:<br>- КоАП РФ 19.4 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.4.1 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.5 статьясы 1 өлеше;<br>- КоАП РФ 19.7 статьясы белән каралган хокук бозулар турында беркетмәләр |
| 10. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече, әйдәп баручы белгече | Статья 3.7. КоАП ТР. Этләрне урамда йөртү тәртибен бозу.<br>Статья 5.1. КоАП ТР. Билетсыз йөрү.<br>Статья 5.2. КоАП ТР. Багаж ташу кагыйдәләрен бозу.<br>Статья 5.6. КоАП ТР. Пассажирны йөртүдән баш тарту. |

Кыскартылган исемнәр:

КоАП РФ – Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турындагы кодексы;

КоАП ТР – Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турындагы кодексы.